ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

Казан ш.

16.06.2017

№ 91

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014-2020 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү" дәүләт программасын раслау турында" 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында туристлык базарының иң яхшы катнашучыларын һәм юнәлешләрен ачыклау максатында боерык бирәм:

1. 2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (Е.Е.Попова) Конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча эшне оештырырга.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча рәис урынбасары А.И. Абдрашитовны җаваплы итеп билгеләргә.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 16.06.2017
№ 91 боерыгы белән
расланды

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсын үткәрү турында

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрүнең һәм оештыруның тәртибен, шартларын, шулай ук Конкурста катнашучыларга, конкурс документларына һәм аларны Конкурска тапшыру тәртибенә карата таләпләрне, Конкурс үткәрү чорларын билгели.

1.2. Конкурсның максаты булып туристлык базарындагы иң яхшы катнашучыларны һәм юнәлешләрне ачыклау, Татарстан Республикасында заманча югары нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле туристлык комплексын төзүнең бурычын хәл итүдә Татарстан Республикасы икътисадын үстерүгә әһәмиятле өлеш тәэмин итүче туристлык бизнесы көчләрен берләштерү һәм көчәйтү тора.

1.3. Конкурсның оештыручысы булып Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тора. Конкурс Конкурс комиссиясе составына кертелүче, Конкурсны оештыручыларның берсе сыйфатында катнашучы туристлык өлкәсендәге кызыксынган оешмалар белән берлектә үткәрелә.

1.4. Конкурсның приз фондын финанслау 2017 елга Дәүләт комитетының керемнәр һәм чыгымнар буенча җыелма сметасында каралган акчалар хисабыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Әлеге Нигезләмә конкурс чаралары тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була.

## 2. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашу түләүсез, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Конкурста Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән (коллектив урнаштыру оешмаларын һәм чараларын, шул исәптән шифаханә-курортта дәвалау һәм ял, танып белү, эшлекле, дәвалау-савыктыру һәм башка юнәлештәге оешмаларны, шулай ук туроператор һәм турагент эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һ.б. кертеп) туристлык индустриясе субъектлары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары, Татарстан Республикасының тармак юнәлешендә белем бирү йортлары, иҗтимагый оешмалар,

массакүләм мәгълүмат чаралары (газеталар, журналлар, радио, телевидение), шулай ук 22 яшьтән башлап 60 яшькәчә булган физик затлар катнаша.

2.2. Номинантларны Конкурста катнашуга этәрү юридик затлар тарафыннан да, физик затлар тарафыннан да гамәлгә ашырыла. Конкурста катнашу бер яисә берничә номинациядә (теләккә карап) гамәлгә ашырыла.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс 2017 елның 01 августыннан 30 декабренә кадәр бер этапта үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Дәүләт комитетының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) конкурс проектларын кабул итә башлаганчыга кадәр 15 календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

3.2. Дәүләт комитетына конкурс документларын тапшыру вакыты 2017 елның 01 августыннан башлап 01 декабренә кадәр.

Конкурс документлары кулдан кулга тапшырыла яисә түбәндәге адрес буенча почта аша җибәрелә: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., М.Горький ур., 19 й. (кабинет № 1).

Конкурс документларының электрон версиясе Конкурсны оештыручының электрон адресына кабатлап җибәрелә – Olga.Neumoina@tatar.ru

3.3. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән, үз вакытында тапшырылган, эчтәлеге һәм рәсмиләштерелеше шушы Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс документлары Конкурста катнашуга кертелә.

3.4. Конкурста катнашу өчен Дәүләт комитетына тутырылган анкета-заявка (формалары кушымтада бирелә) һәм шушы Нигезләмәнең 3.6 пунктчасында күрсәтелгән документлар номинацияләргә туры китереп тапшырыла.

3.5. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) "Ел ачышы – 2017"

2) "Татарстан Республикасы туристлык базары үсешенә ярдәм итү" –түбәндәге бүлекләр буенча:

"Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә – 2017";

"Туристлык буенча белем бирү өлкәсендә – 2017";

"Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә – 2017" – түбәндәге бүлекләр буенча:

Татарстан Республикасының кучмә һәм эчке туристлыгын популярлаштыруга багышланган иң яхшы материал,

Татарстан Республикасының шифаханә-курорт мөмкинлекләрен популярлаштыруга багышланган иң яхшы материал.

3) "2017 ел персонасы – туристлыкны үстерүдә шәхси кертем өчен".

4) "Татарстан Республикасы буенча 2017 елның иң яхшы маршруты".

5) "Татарстан Республикасының 2017 елда иң яхшы туроператоры".

6) "2017 елның иң яхшы туристлык волонтеры".

7) "2017 елның иң яхшы экскурсиячесе".

8) "2017 ел туристлык сувенирлы".

9) "Татарстан Республикасы урнаштыру предприятиесе – 2017" – түбәндәге бүлекләр буенча:

"2017 елның иң яхшы 5* отеле";

"2017 елның иң яхшы 4* отеле";

"2017 елның иң яхшы 3* отеле";

"2017 елның иң яхшы 2* отеле";

"2017 елның иң яхшы хостеле";

"2017 елның иң яхшы шифаханәсе";

"2017 елның иң яхшы ял базасы";

"2017 елның иң яхшы мотеле".

10) "2017 ел рестораны".

3.6. "Ел ачышы – 2017" номинациясендә катнашу өчен Конкурска, туристлык өлкәсендә 2017 елда тормышка ашырылган проектны теркәп, анкета-заявка (1 нче кушымта) тапшырыла.

"Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы туристлык базары үсешенә ярдәм итү – 2017" номинациясендә Татарстан Республикасы туристлыгы үсешенә өлеш керткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары анкета-заявкада (2 нче кушымта) китерелгән махсус күрсәткечләр буенча бәяләнә.

"Туристлык буенча белем бирү өлкәсендә Татарстан Республикасы туристлык базары үсешенә ярдәм итү – 2017" номинациясендә Татарстан Республикасының тармак буенча белем бирү йортлары анкета-заявкада (3 нче кушымта) китерелгән махсус күрсәткечләр буенча бәяләнә.

"Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы туристлык базары үсешенә ярдәм итү – 2017" номинациясендә Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чаралары (газеталар, журналлар, радио, телевидение) бәяләнә. Конкурска, 2017 елда басылып чыккан материалларны теркәп, анкета-заявка (4 нче кушымта) тапшырыла.

"2017 ел персонасы – туристлыкны үстерүгә шәхси кертем өчен" номинациясендә катнашу өчен Конкурска йә физик заттан, йә оешма исеменнән тутырылган анкета-заявка (5 нче кушымта) тапшырыла.

Конкурста катнашучыларга карата 2017 елда Татарстан Республикасының түбәндәге контрольлек органнары тарафыннан дәгъваларның булмавы Конкурста

катнашуның зарури шарты булып тора: Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе.

"Татарстан Республикасы буенча 2017 елның иң яхшы маршруты", "Татарстан Республикасының 2017 елда иң яхшы туроператоры", "2017 елның иң яхшы туристлык волонтеры", "2017 елның иң яхшы экскурсиячесе", "2017 ел туристлык сувениры", "2017 елда Татарстан Республикасы урнаштыру предприятиесе", "2017 ел рестораны" номинацияләре буенча Конкурс Конкурсны оештыруда катнашучылар тарафыннан шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктына туры китереп үткәрелә.

Конкурсны оештыруда катнашучылар Конкурс турында нигезләмәне раслыйлар, Конкурсны үткәрүнең һәм оештыруның тәртибен, шартларын, Конкурста катнашучыларга, конкурс документларына һәм аларны Конкурска тапшыру тәртибенә карата таләпләрне, Конкурсны үткәрү вакытларын билгелиләр.

"Татарстан Республикасы буенча 2017 елның иң яхшы маршруты" һәм "Татарстан Республикасының 2017 елда иң яхшы туроператоры" номинацияләре буенча Конкурс үткәрүне оештыруда Татарстан Республикасының Туристлык агентлыклары ассоциациясе катнаша.

"Татарстан Республикасы буенча 2017 елның иң яхшы маршруты" һәм "Татарстан Республикасының 2017 елда иң яхшы туроператоры" номинацияләре буенча Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматлар Татарстан Республикасы Туристлык агентлыклары ассоциациясенең "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://atart.ru) урнаштырыла.

"2017 елның иң яхшы туристлык волонтеры" номинациясе буенча Конкурс үткәрүне оештыруда "Татарстан Республикасы Туристлык волонтерлары ассамблеясе" автономияле коммерциячел булмаган оешмасы катнаша.

"2017 елның иң яхшы туристлык волонтеры" номинациясе буенча Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматлар "Татарстан Республикасы Туристлык волонтерлары ассамблеясе" автономияле коммерциячел булмаган оешмасының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге "ВКонтакте" һәм "Инстаграм" (https://vk.com/atv2009, @atv_volunteers) рәсми битләрендә урнаштырыла.

"2017 елның яң яхшы экскурсиячесе" номинациясе буенча Конкурс үткәрүне оештыруда "Татарстан экскурсиячеләре ассоциациясе" коммерциячел булмаган партнерлыгы катнаша.

"2017 елның яң яхшы экскурсиячесе" номинациясе буенча Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматлар "Татарстан экскурсиячеләре ассоциациясе" коммерциячел

булмаган партнерлыгының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://kazantravel.ru) урнаштырыла.

"2017 ел туристлык сувенирлы" номинациясе буенча Конкурс үткәрүне оештыруда "Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерү үзәге" дәүләт бюджет учреждениесе, "Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре палатасы" коммерциячел булмаган партнерлыгы катнаша.

"2017 ел туристлык суыенирлы" номинациясе буенча Конкурс үткәрелү турындагы мәгълүматлар "Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерү үзәге" дәүләт бюджет учреждениесенең "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://remeslo.tatarstan.ru) урнаштырыла.

"2017 елда Татарстан Республикасы урнаштыру предприятиесе" һәм "2017 ел рестораны" номинацияләре буенча Конкурсларны үткәрүдә "Татарстан Республикасының туристлыкны үстерү үзәге" автономияле коммерциячел булмаган оешмасы, "S-Luxstudio" компаниясе, "Линия Вкуса" компанияләре төркеме катнаша.

"2017 елда Татарстан Республикасы урнаштыру предприятиесе" һәм "2017 ел рестораны" номинацияләре буенча Конкурсларны үткәрү турындагы мәгълүматлар "Татарстан Республикасының туристлыкны үстерү үзәге" автономияле коммерциячел булмаган оешмасының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tdc-tatar.ru) урнаштырыла.

3.7. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән датадан соң тапшырылган конкурс документлары каралмый һәм Конкурста катнашуга кертелми.

3.8. Конкурска җибәрелгән барлык материаллар да кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Конкурста сайлап алу тәртибе

4.1. Килгән конкурс проектларын бәяләү максатында Дәүләт комитеты тарафыннан Конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

4.2. Комиссиянең шәхси составы Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының боерыгы белән, кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм иҗтимагый оешмаларының вәкилләреннән, шул исәптән шушы Нигезләмәнең 3.6 пунктчасында күрсәтелгән номинацияләр буенча Конкурсларны үткәрүдә катнашучы вәкилләрдән Комиссиянең рәисе җитәкчелегендә, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатибе катнашындагы 16 кешелек составта раслана.

4.3. Комиссиянең эшенә рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда аның вазыйфалары урынбасарына йөкләнә. Өстәмә рәвештә экспертлар җәлеп итү хокукын Комиссия үз ихтыярында калдыра. Конкурс нәтиҗәләре турында шәхсән кызыксынган затлар Комиссия әгъзалары була алмыйлар.

4.4. Комиссиянең эше утырышта гамәлгә ашырыла. Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, утырыш тулы хокуклы булып санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.5. Комиссиянең җаваплы сәркатибе түбәндәге функцияләрне үти:

шушы Нигезләмәнең 3.1-3.4 пунктларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, материалларны кабул итә һәм терки, һәм аларның саклануын тәэмин итә;

Комиссиянең утырышын оештыра, документларны әзерли һәм беркетмә рәсмиләштерә.

4.6. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан әгъзалар тарафыннан бирелгән тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәислек итүче һәм җаваплы сәркатип кул куя. Тавышлар саны тигез булганда, рәиснең тавышы хәл иткеч булып санала.

4.7. Конкурста катнашучы Конкурс нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, ул Конкурс комиссиясенә апелляция бирү хокукына ия.

Апелляция язмача рәвештә ирекле формада Комиссия рәисе исеменә Комиссия беркетмәсе Дәүләт комитеты сайтында бастырып чыгарылганнан соң өч эш көне эчендә тапшырыла. Ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында тапшырылган апелляцияләр Комиссия әгъзаларына җибәрелә.

Комиссия әгъзалары апелляцияләр килү чоры тәмамланган көннән соңгы дүрт эш көне эчендә аларны карап тикшерәләр һәм коллегиаль рәвештә фикер алышалар. Карар ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш туплау нигезендә кабул ителә һәм Комиссиянең катнашкан әгъзалары күпчелекне тәшкил иткәндә, легитимлы булып таныла. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәл итүле була. Комиссиянең җаваплы сәркатибе Комиссия карары нигезендә беркетмә рәсмиләштерә. Беркетмәдә Комиссиянең һәр әгъзасының фикере һәм гомуми йомгак күрсәтелә:

апелляцияне канәгатьләндермәү һәм бастырып чыгарылган нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Беркетмәгә Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатип кул куя.

Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия карары иң соңгысы була, ул яңадан каралмый һәм суд тәртибендә шикаять кылынырга мөмкин.

## 5. Конкурста җиңүчеләр

5.1. Конкурста җиңүчеләр һәм дипломантлар Конкурс комиссиясе утырышында билгеләнә. Комиссия Конкурста катнашучылар каршысында бәяләрне нигезләми.

5.2. Конкурсның һәр номинациясендә (һәр бүлектә берәр) бер җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр Дәүләт комитеты исеменнән махсус дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә.

Үткәрелүче Конкурс кысаларында Дәүләт комитеты тарафыннан эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә махсус казанышлар өчен махсус призларны гамәлгә кую рөхсәт ителә.

5.3. Заявка составындагы материалларны эшкәрткәндә һәм анализлаганда, аларның объектив булу-булмавын бәяләгәндә Конкурс комиссиясе әгъзалары ун баллы шкала буенча бәяләү процессында үзара ышану, шәхсән җаваплы һәм таләпчән булу принципларыннан чыгып эш итә (1 балл – иң түбән билге, 10 балл – иң югары билге).

5.4. Һәр критерий буенча Конкурс комиссиясе әгъзасы ун баллы шкала буенча билге куя. Һәр критерий буенча билгеләрнең суммасы Конкурста катнашучыга гомуми билгене бирә.

5.5. "Ел ачышы – 2017" һәм "2017 ел персонасы – туристлыкны үстерүдә шәхсән кертем өчен" номинацияләре буенча җиңүчеләр тавыш бирү йомгаклары буенча тавышларны гади рәвештә исәпләп чыгару юлы белән билгеләнә.

5.6. "Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы туристлык базары үсешенә ярдәм итү" номинациясендә – "Татарстан Республикасының күчмә һәм эчке туристлыгын популярлаштыруга багышланган иң яхшы материал" халыкара туристлык күргәзмәсенә бару рәвешендәге махсус приз белән бүләкләнә (шушы Нигезләмәнең 5.2 пункты).

5.7. "Татарстан Республикасы буенча 2017 елның иң яхшы маршруты", "Татарстан Республикасының 2017 елда иң яхшы туроператоры", "2017 елның иң яхшы туристлык волонтеры", "2017 елның иң яхшы экскурсиячесе", "2017 ел туристлык сувенины", "2017 елда Татарстан Республикасы урнаштыру предприятиесе", "2017 ел рестораны" номинацияләре буенча җиңүчеләр Конкурсны оештыруда катнашучылар тарафыннан шушы Нигезләмәнең 3.6 пунктына туры китереп, үткәрелгән Конкурс йомгаклары буенча билгеләнә.

5.8. Конкурсны оештыручы белән алдан килештереп, кызыксынган оешмалар тарафыннан үткәрелүче Конкурс кысаларында махсус казанышлар өчен катнашучыларга өстәмә призлар һәм бүләкләр тапшырыла.

5.9. Конкурс нәтиҗәләре Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе нигезендә, аңа имза салынган көннән соңгы эш көннәрендә исәпләнүче 3 көнлек чорда Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.10. Конкурс йомгаклары Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыруның Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) оештырыла торган тантанасында 2017 елның 30 декабреннән дә соңга калмыйча әйтелә. Конкурс йомгаклары турында игълан Татарстан Республикасы Туристлык

буенча дәүләт комитетының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасы үткәрелгән көнне бастырып чыгарыла.

5.11. Конкурсны оештыручы түбәндәгеләрне үз ихтыярында калдыра:

тапшырылган конкурс материалларын үзәк, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару хокукын;

материалларны челтәрләрле теле- һәм радиокомпанияләрнең эфирларында урнаштыру хокукын;

5.12. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс документларын җибәрү факты белән шушы Нигезләмәнең барлык шартлары белән дә тулысынча һәм берсүзсез риза булуларын раслыйлар.

5.13. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс документларын җибәрү факты белән үзләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкларын раслыйлар.

2017 елда "Туристлык лидеры"
республика конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсында катнашучыдан
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинация:** ***ЕЛ АЧЫШЫ***

**1. Тутыру датасы** ____________________________
**2. Оешманың тулысынча аталышы** ___________________________________________
____________________________________________________________________________
**3. Адресы**_____________________________________________________________________
**4. Лицензиясе** ___________________________________________________________________
**5. Директорының Ф.И.А.**
____________________________________________________________
**6. Элемтә телефоны** _________ **факс** ______________ **E-mail** __________________
**7. Web-сайты** ___________________________________________________________________
**8. Проектка сыйфатлама**

**9. Татарстан Республикасында туристлыкны үстерүдәге әһәмияте**

**10. Бүләкләүләр, бастырып чыгарылган мәкаләләр, проект турында кайтавазлар**

**11. Конкурс комиссиясе йомгаклары**

Искәрмә: Кара сызык белән аерып чыгарылган урыннар конкурс комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2017 елда "Туристлык лидеры"
республика конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсында катнашучыдан
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинация: Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ***

**1. Тутыру датасы ___________________________**
**2. Оешманың тулысынча атальшы ________________________________________**
**3. Адресы______________________________________________________________________________**
**4. Нигез салыну датасы _________________________________________________________________**
**5. Җитәкчесенең Ф.И.А.___________________________________________________________________**
**6. Элемтә телефоны _________ факс _____________ E-mail _________________**
**7. Web-сайты __________________________________________________________________________**

| **8. 2017 ел өчен эш күрсәткечләре** | **Күрсәткечнең әһәмияте** | **Урыны** |
|---|---|---|
| Туристлар санына экспертлык билгесе, кеше. | | |
| Туристларга күрсәтелгән хезмәтләр күләме, сум. | | |
| **Районның туристлык паспорты булу** | | |
| Web-сайты булу – баллар саны | | |
| Күрсәтмә материаллар һәм реклама продуктлары саны – баллар саны | | |
| **ҖӘМГЫСЕ:** | | |

| | |
|---|---|
| **9. Муниципаль районда туристлыкны үстерү буенча проект/программа** | **Тасвирлама** |
| **10. Белешмә өчен:** | |
| Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү буенча чараларда катнашу (күрсәтергә) | |
| Муниципаль берәмлек территориясендә вакыйгалы туристлык чараларын үткәрүдә туристлар санына экспертлык билгесе, кеше. | |
| Туристлыкны үстерү программалары, перспективалы проектлар булу, аларны тормышка ашыру | |
| МБ мәгълүмати туристлык үзәге булу, әйе/юк | |
| Туристлык базарында МБ алга этәрү формасы (күрсәтергә) | |
| Эшчәнлектәге яңа формалар (күрсәтергә) | |
| **Конкурс комиссиясенә презентация продуктлары, шул исәптән булган барлык чит телләрдә тапшырыла** | |
| **11. Конкурс комиссиясе йомгаклары** | |

Искәрмә: Кара сызык белән аерып чыгарылган урыннар конкурс комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2017 елда "Туристлык лидеры"
республика конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсында катнашучыдан
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинация: Туристлык буенча һөнәри белем бирү өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ***

**1. Тутыру датасы** ___________________________
**2. Оешманың тулысынча аталышы** ________________________________________
**3. Адресы**________________________________________________________________
**4. Нигез салыну датасы** ____________________________________________________
**5. Лицензиясе** _____________________________________________________________
**6. Аккредитациясе** _________________________________________________________
**7. Сертификаты** ___________________________________________________________
**8. Җитәкчесенең Ф.И.А.**____________________________________________________
**9. Элемтә телефоны** _________ **факс** _____________ **E-mail** _________________
**10. Web-сайты** ____________________________________________________________

| **11. 2017 ел өчен эш күрсәткечләре** | **Күрсәткечнең әһәмияте** | | **Урыны** |
|---|---|---|---|
| | План буенча | Фактта | |
| 1. Туристлык белгечлекләре буенча белем алучыларның гомуми саны, кеше, ш.и. (белгечлекләр буенча бүлгәләү) | | | |
| - | | | |
| - | | | |
| Алардан шартнамәләр буенча:<br>- турфирмалар белән;<br>- кунакханәләр белән | | | |
| 2. 2016/17 уку елында туристлык белгечлекләре буенча укытып чыгарылган укучылар (кешеләр саны) | | | |
| 3. Турфирмалар белән бәйләнешләр формасы (күрсәтергә) | | | |
| 4. Кунакханәләр белән бәйләнешләр формасы (күрсәтергә) | | | |
| 5. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Туриндустрия өлкәсендә кадрларны әзерләүдә ярдәм күрсәтү буенча методик советы чараларында катнашу (күрсәтергә) | | | |
| 6. Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү буенча 2017 елда тормышка ашырылган проектлар (ниндиләр булуын күрсәтергә) | | | |
| 7. Туристлык базарында алга этәрү формалары (күрсәтергә) | | | |
| 8. Эшчәнлектәге яңа формалар (күрсәтергә) | | | |
| **9. Конкурс комиссиясе йомгаклары** | | | |

Искәрмә: Кара сызык белән аерып чыгарылган урыннар конкурс комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2017 елда "Туристлык лидеры"
республика конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсында катнашучыдан
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинация:** ***<u>Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ</u>***

**1. Тутыру датасы** ____________________________________________________
**2. Авторның Ф.И.А.**____________________________________________________
**3. Эш урыны, вазыйфасы**_____________________________________________
**4. Мәкаләнең исеме (баш исеме)**________________________________________
**5. ММЧ аталышы**_____________________________________________________
**6. Басылып чыгу датасы**
________________________________________________________
**7. Мәкаләгә сылтама** __________________________________________________
**8. Элемтә телефоны** ___________________ **E-mail** __________________________

**2. Кушымталар:**

- басма ММЧ басылып чыккан материаллар – мәкаләнең PDF форматындагы сканы, материалның басылып чыгу датасын, авторның (авторларның) исемен таныклый торган массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе тарафыннан таныкланган редакция белешмәсе;
- TV дагы видеосюжет – видеосюжетка сылтама;
- Интернет челтәрендәге мәкалә – битләрнең скриншоты.

**3. Конкурс комиссиясе йомгаклары**

**Катнашучыларның эшләренең сыйфатын бәяләү критерийлары**

- белдерелгән номинациягә туры килүе,
- конкурс темасын материалда иң тулы һәм кызыклы итеп чагылдыру,
- бәян ителгәннең төгәллеге һәм теленең аңлаешлы булуы.
- профессиональлек (материалның вәкаләтлелеге, тирәнлеге, актуальлеге)

Искәрмә: Кара сызык белән аерып чыгарылган урыннар конкурс комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2017 елда "Туристлык лидеры"
республика конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

2017 елда "Туристлык лидеры" республика конкурсында катнашучыдан
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинация:** ***ЕЛ ПЕРСОНАСЫ – туристлыкны үстерүдә шәхси кертем өчен***

**1. Тутыру датасы** ____________________________________________

**2. Катнашучының Ф.И.А.**
____________________________________________

**3. Туган көне, ае, елы**____________________________________________

**4. Эш урыны һәм вазыйфасы** (булганда) ______________________________

**5. Туристлык өлкәсендәге эш стажы**
___________________________________

**6. Һөнәрендәге шәхси казанышлары:**

**7. Конкурс комиссиясе йомгаклары**

Искәрмә: Кара сызык белән аерып чыгарылган урыннар конкурс комиссиясе тарафыннан тутырыла.